**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 1 сентябрендәге 3037 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2019 елның 19 мартындагы 858 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыруның компенсацияле урыннары реестрын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль законнар, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.33, 39.36 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында»гы карары (аңа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы, 2019 елның 17 июнендәге 498 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) нигезендә карар бирәм:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 мартындагы 858 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыруның компенсацияле урыннары реестрын раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 11 июнендәге 2136 номерлы, 2019 елның 26 ноябрендәге 4183 номерлы, 2021 елның 22 октябрендәге 2747 номерлы, 2022 елның 28 апрелендәге 1267 номерлы,

2023 елның 13 февралендәге 458 номерлы, 2025 елның 829 октябрендәге 3751 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтадагы таблицага түбәндәге эчтәлекле юлларны өстәп, түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

| **Реестр номеры** | **Факттагы адресы** | **Факт буенча профиле** | **Мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|---|
| «А-18 | Беломорск урамы, 22 номерлы йорт янында | Җәмәгать туклануы | 100 дән артык түгел |
| А-19 | Беломорск урамы, 26 номерлы йорт янында | Азык-төлек | 165 дән артык түгел |
| А-128 | Максимов урамы, 47 номерлы йорт янында | Азык-төлек булмаган | 60 тан артык түгел |
| А-143 | Максимов урамы, 7 номерлы йорт янында | Чәчәкләр | 60 тан артык түгел |
| А-151 | Гудованцев урамы, 130 номерлы йорт янында | Азык-төлек | 200 дән артык түгел |
| А-152 | Гудованцев урамы, 130 номерлы йорт янында | Җәмәгать туклануы | 200 дән артык түгел» |
| «П-175 | Академик Парин урамы, 6 номерлы йорт янында | Җәмәгать туклануы | 60 тан артык түгел |
| П-181 | Профессор Камай урамы, 1 номерлы йорт янында | Азык-төлек | 60 дән артык түгел» |
| «М-81 | Серов урамы, 6 номерлы йорт янында | Икмәк-күмәч ризыклары | 20 дән артык түгел» |

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**